Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Красный Ключ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2021 елның 25 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 24 - 25 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге Красный Ключ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге (уку йортына йөреп уку) уку студентларыннан тыш; 2 нче төркем инвалидларына һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерларга, күп балалы гаиләләргә 50% түләү белән, 300 суммасында 2022 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Красный Ключ поселогындагы «Сугышчылар» Мемориалын ремонтлау (материаллар, кече архитектура формалары сатып алу, килешү, контракт буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Җыен нәтиҗәләре турында йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 2168 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 1237 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 1018 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 219 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Красный Ключ торак пунктында гражданнар җыенын узды дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Красный Ключ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге (уку йортына йөреп уку) уку студентларыннан тыш; 2 нче төркем инвалидларына һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерларга, күп балалы гаиләләргә 50% түләү белән, 300 суммасында 2022 елда үзара салым кертү белән

килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Красный Ключ поселогындагы «Сугышчылар» Мемориалын ремонтлау (материаллар, кече архитектура формалары сатып алу, килешү, контракт буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Красный Ключ авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Красный Ключ авыл җирлеге башлыгы И.К.Зәйнетдинов

СОВЕТ КРАСНО-КЛЮЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ